СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2023 елның 13 сентябре № 31/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2014 елның 16 октябрендәге 44/2 номерлы карары белән (01.04.2015 № 49/8, 31.05.2022 № 19/3 үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәгә, **16 пунктның икенче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәткәрләрнең үз чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү, яисә федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, үз чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү, яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү, яисә,

хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында дөрес булмаган белешмәләр тапшыру, әгәр дә мондый мәгълүматны тапшыру мәҗбүри булса, аларны биләгән вазыйфасыннан, муниципаль хезмәттән билгеләнгән тәртиптә азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров